| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

31.08.2018 №967

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

"Татарстан Республикасы дәүләт мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында" №413 31.05.2018 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән туры китереп Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районы муниципаль китапханәләрнең**,** мәдәни-ял итү учреждениеләре, Туган якны өйрәнү музее мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында Кагыйдәнамәне расларга (алда- Кагыйдәнамә);

2. Әлеге карарга №1 Кушымтада бәян ителгән Кагыйдәнамә нигезендә, 2018нче елның 1нче сентябреннән хезмәткә яңача түләү системасын кертергә;

3. Югары Ослан муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакы урындагы вазифалары күләмен саклаган һәм шул ук квалификация эшләрен башкарган шартларда хезмәткәрләрнең әлеге карар белән туры китереп хезмәткә түләү шартларына күчү моментына гамәлдә булган хезмәткә түләү системасы нигезендә түләнгән хезмәт хакыннан ким була алмый;

4. Муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә МКУ "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәдәният бүлеге" (алда - МКУ "Мәдәният

бүлеге”) һәм Югары Ослан муниципаль районы мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең профсоюз оешмалары белән килешү буенча Югары Ослан муниципаль районы мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартларын билгеләүче коллектив килешүләргә, шартнамәләргә, локаль норматив хокук актларына тиешле үзгәрешләрне кертергә;

5. “Мәдәният учреждениеләре, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең хезмәтенә яңача түләү системасын кертү турында” №1155 09.08.2012 Башкарма комитет Җитәкчесе карары көчен югалткан дип танырга;

6. МКУ “Мәдәният бүлеге” башлыгына Әлеге карарның 1нче пунктында бәян ителгән Кагыйдәнамә нигезендә яңа тарификация белән туры китереп хезмәт хакын исәпләргә;

7. Әлеге карарның 1нче пункты 2018нче елның 1нче сентябреннән көченә керә дип билгеләргә;

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча җитәкче ярдәмчесенә йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**Җитәкчесе** **Л.С. Хакимзянов**

Әзерләде һәм җибәрде
Р.З.Нефедова
3 экз.

Кушымта
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
№ 967 31.08.2018 карары белән расланды

**Югары Ослан муниципаль районы муниципаль китапханәләрнең , мәдәни-ял итү учреждениеләре, Туган якны өйрәнү музее мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында**

## Кагыйдәнамә

### I. Гомуми кагыйдәнамәләр

Югары Ослан муниципаль районы муниципаль китапханәләрнең, мәдәни-ял итү учреждениеләре, Туган якны өйрәнү музее мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында әлеге Кагыйдәнамә (алда- Кагыйдәнамә) хезмәткәрләрнең окладларын формалаштыруны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм шартларын, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

1.1. Әлеге Кагыйдәнамәдә түбәндәге билгеләмәләр һәм төшенчәләр кулланыла:

хезмәткә түләү системасы - база окладларын, вазыйфаи окладларны, шулай ук федераль кануннар һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары белән туры китереп билгеләнгән компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне кертеп учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары һәм күләмен билгеләүче норма җыелмасы;

база оклад, база хезмәт хакы ставкасы - оклад, эшче һөнәре буенча яки җитәкче вазифасы буенча профессиональ эшчәнлекне тормышка ашыручы учреждение хезмәткәренең, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпкә алмыйча тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче белгеч, техник башкаручы хезмәт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпкә алмыйча, ставканы исәпкә алып, календарь ае өчен билгеле бер кыенлыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен хезмәткәрнең беркетелгән хезмәт хакы күләме;

хезмәткәрнең хезмәт хакы (хезмәткә түләү) - хезмәткәр квалификациясенә карап башкарылган эш күләме, сыйфаты һәм шартларына бәйле рәвештә хезмәт өчен түләү, шулай ук компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр;

компенсация характерындагы түләүләр - компенсация характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, шул исәптән нормаль эштән читкә китү шартларында эшләгән өчен, һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

кызыксындыру характерындагы түләүләр - кызыксындыру характерындагы өстәмәләр һәм өстәмә түләүләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

1.2. Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләре, сәнгать һәм кинематография,

дәүләт китапханәләре, музейлар, музей төрендәге башка учреждениләрнең һәм мәдәни-ял итү учреждениеләре (алда- мәдәният хезмәткәрләре ) хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәтенә түләү) түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

окладлар (вазифаи окладлар), хезмәт хакы ставкасы;

компенсация характерындагы түләүләр;

кызыксындыру характерындагы түләүләр .

1.3 Профиль буенча эш стажы арту сәбәпле, белем алу белән яки белем турында документларны торгызу, квалификация категориясе бирелү белән, мактаулы исем бирелү белән, ведомство аерымлык билгеләре белән бүләкләү, ел саен яки башка отпускта булу чорында, вакытлыча эшкә яраксызлык чорында, алар дәвамында уртача хезмәт хакы сакланган башка чорларда хезмәткәрдә хезмәт хакы күләмен үзгәртүгә хокук туганда аның хезмәте өчен түләү күләмен үзгәртү күрсәтелгән чорлар тәмамлангач гамәлгә ашырыла.

## II. Мәдәният хезмәткәрләре хезмәтенә түләүнең база окладларын билгеләү

| Вазыйфаның исеме | Аена база окладының күләме , сум | | |
|---|---|---|---|
| | Төп гомуми белем, урта гомуми белем | Квалификацияле эшчеләр хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | Аттестацияне уңышлы узган затка бирелгән югары һөнәри белем, «бакалавр», «магистр» квалификациясе яки «дипломлы белгеч» |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| «Урта звено мәдәният хезмәткәрләре» профессиональ квалификация төркеме | | | |
| Түгәрәк җитәкчесе, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксыну клубы | 9 500 | 12 350 | 14915 |
| Аккомпаниатор | 9 500 | 12 350 | 14915 |

| « Әйдәп баручы мәдәният хезмәткәрләре вазыйфасы» профессиональ квалификация төркеме | | | |
|---|---|---|---|
| Китапханәче | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Тавыш операторы | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждение һәм организация мөхәррире. | | 12 484 | 15 343 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждение һәм организация методисты | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Библиограф | 9 530 | 12 484 | 15 343 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Рәссам-бизәүче | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Әйдәп баручы китапханәче | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Әйдәп баручы библиограф | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Клуб учреждениесе мөхәррире | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Клуб учреждениесе, халык иҗаты фәнни - методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте үзәге (мәдәният һәм ял) һәм башка шундый учреждение һәм организация методисты. | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Китапханәнең, музейның һәм башка шундый учреждение һәм организациянең әйдәп баручы методисты | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Баш китапханәче | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Төп библиограф | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| Фондларны саклаучы | 9 530 | 12 484 | 15 343 |
| « Мәдәният учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы» профессиональ квалификация төркеме | | | |
| Музейның бүлек (секторы) мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Китапханәнең бүлек (секторы) мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Мәдәният йортының бүлек (секторы) һәм башка мәдәни-ял оешмалары мөдире | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Сәнгать җитәкчесе | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Клуб формалаштыру, һәвәскәрләр берләшмәсе, студия, үзешчән сәнгать коллективы, кызыксыну клубы җитәкчесе. | 9 550 | 12 797 | 15 662 |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | 9 550 | 12 797 | 15 662 |

## III. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын формалаштыру тәртибе.

3.1. Мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Od = Oь \times S,$$

монда:

$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$0_ъ$ – әлеге Кагыйдәнамәнең 2нче бүлеге белән туры китереп кабул ителгән мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары күләме;

$S$ - мәдәният хезмәткәре биләгән ставкаларның факттагы саны.

3.2. Алып торган вазифа югары белем- бакалавриат яки специалитет яки магистратура, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, югары белемле затлар биләгән вазыйфалар буенча- бакалавриат яки специалитет яки магистратура , урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем таләп итмәгән очракта, урта гомуми белемгә туры килүче хезмәт хакын түләү тәртибе билгеләнә.

3.3. Вазыйфаларга квалификация таләпләре төрле дәрәҗәдәге белемне күз алдында тоткан очракта, фактта булган белем дәрәҗәсенә туры килгән хезмәт хакын түләү тәртибе билгеләнә.

3.4. Белем дәрәҗәсен үзгәрткән очракта мәдәният хезмәткәре окладына тиешле дәрәҗәдәге белем алу турында дәүләт үрнәгендәге документ биргән вакыттан алып төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## IV.Кызыксындыру характерындагы түләү

4.1. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә хезмәт кешесенең сыйфатлы хезмәт нәтиҗәләренә стимуллаштыруга юнәлдерелгән түләүләр, шулай ук башкарылган эшләр өчен кызыксындыру керә.

4.2. Кызыксындыру характерындагы түләү үз эченә ала:

эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү;

мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булган өчен түләүләр;

квалификация категориясе өчен түләүләр;

профиль буенча эш стажы өчен түләү;

башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләр;

премиаль һәм башка кызыксындыру түләүләре.

4.3. Эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү мәдәният, сәнгать һәм кинематографиянең һөнәри квалификация төркемнәренең урта, әйдәп баручы һәм аерым учреждениеләрдә җитәкчелек составының вазыйфалары хезмәткәрләренә бирелә һәм формула буенча исәпләнә:

$$Bsd = Od \times D_{Sd},$$

монда :

$B_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен түләү -;

$0_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{sd}$ - эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләү күләме.

Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә түләүләр күләме 1нче таблицада бирелгән .

4.4. Әлеге учреждениедә, бүлекчәдә һәм вазыйфада конкрет эш шартлары исәпкә алынган эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмәләр билгеләнгән мәдәният хезмәткәрләре вазыйфалары исемлеге сайлау профсоюз органы белән килешү буенча һәр учреждение (яки башка мәдәният хезмәткәрләре мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтле органы) тарафыннан раслана.

1нче таблица

Эшчәнлекнең үзенчәлеге өчен тәкъдим ителә торган өстәмәләр күләме

| № | Эшчәнлек үзенчәлеге өчен өстәмә билгеләү нигезләре | Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|---|
| 1. | Физик үсеш җитешсезлекләре булган затларга хезмәт күрсәтү (сукырлар,чукраклар) | урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |
| | | әйдәп баручы звеноның мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары | 5 |

4.5. Мактаулы исемнәр булган өчен, дәүләт бүләкләре өчен түләүләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә кергән хезмәткәрләргә бирелә, һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Bpz = Od \; X \; Dp_{Z}'$$

монда:

$B_{pz}$ - мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булу өчен түләү;

$Od$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булу өчен өстәмә түләүләр күләме.

4.6. Мактаулы исемнәр, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре булу өчен, СССР составындагы автоном республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә түләүләр күләме 8 процент.

Россия Федерациясе, СССР, СССР составындагы Союз республикалары мактаулы исемнәре булу өчен 10 процент.

Алар буенча кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре, СССР, СССР составындагы Союз һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре исемлеге әлеге Кагыйдәнамәгә кушымтада бирелә.

4.7. Мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булу өчен түләүләр күләмен билгеләү мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исемнәре булган, ике һәм аннан да күбрәк Дәүләт бүләкләре булган хезмәткәргә, мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре булу өчен түләү, хезмәткәрнең сайлауы буенча мактаулы исемнәрнең, дәүләт бүләкләренең берсе буенча билгеләнә

4.8. Квалификация категориясенә түләүләр тариф-квалификация характеристикалары нигезендә профессиональ-квалификация төркемнәре аттестация нәтиҗәләре буенча квалификация категорияләре бирү күздә тоткан белгечлекләре буенча хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Вкк = Od \times D_{kk},$$

монда:

$В_{кк}$ - квалификация категориясе өчен түләү;

$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{kk}$ – квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме.

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме 2нче таблицада бирелгән .

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла.

2нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә түләүләр күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|
| Әйдәп баручы звено мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | |
| 2нче квалификация категориясе | 2 |
| 1нче квалификация категориясе | 4 |
| Югары квалификация категориясе,шулай ук «баш» чыгарылма исеме белән вазифа | 6 |

4.9. Профиль буенча эш стажы өчен түләү һөнәри квалификация төркемнәре буенча профиль буенча эшнең дәвамлылыгына карап билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times D_s,$$

монда :

$B_s$ — профиль буенча эш стажы өчен түләү ;

$0_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_s$ - профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләү күләме.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме 3нче таблицада бирелгән.

Профиль буенча эш стажы өчен өстәмә түләүләр күләме

3нче таблица

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Урта звено мәдәният хезмәткәрләре вазыйфасы | 3тән 10 елга кадәр | 12 |
| | 10нан 15 елга кадәр | 14 |

| | | |
|---|---|---|
| | 15тән 20 елга кадәр | 16 |
| | 20дән 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Әйдәп баручы буын мәдәният хезмәткәрләре вазыйфасы | 3 тән 10 елга кадәр | 12 |
| | 10нан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15тән 20 елга кадәр | 16 |
| | 20дән 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |
| Мәдәният учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы | 3тән 10 елга кадәр | 12 |
| | 10нан 15 елга кадәр | 14 |
| | 15тән 20 елга кадәр | 16 |
| | 20дән 25 елга кадәр | 18 |
| | 25 елдан артык | 22 |

4.10. Вазыйфалар (һөнәрләр) исемлеге, вазыйфасы (белгечлеге) буенча эш стажына исәпләнгән эш вакыты, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән раслана.

4.11. Эш стажы үзгәргәндә профиль буенча эш стажы өчен түләү күләмен билгеләү (үзгәртү), әгәр стажны раслаучы документлар учреждениедә булса, профиле буенча эш стажы өчен түләү күләмен арттыру хокукын бирүче стаж җиткән көннән, яки стажын раслаучы кирәкле документны тапшырган көннән башкарыла.

4.12. Мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә башкарылган эшләр сыйфаты өчен премиаль түләүләр хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеле бер вакыт (ай, квартал, ел) өчен билгеләнә.
Башкара торган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләү күләменә йогынты ясаучы төп критерий булып Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән расланган мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик әһәмиятенә ирешү булып тора.

4.13. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары аның җитәкчесе тарафыннан раслана. Мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының конкрет билгеләре һәм түләүләрне тормышка ашыру шартлары учреждение алдында торган бурычлардан чыгып ел саен билгеләнә.

4.14. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премия түләүләрен гамәлгә ашыру күләме, тәртибе һәм шартлары учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә..

4.15. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләр һөнәри квалификация төркемнәре буенча билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Вк = Od \times Dk>$$

монда:
$B_к$ — башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен премиаль түләүләр;
$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары ;
$D_s$ - башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме .

Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме 4нче таблицада китерелгән.

4нче таблица

Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен өстәмә түләүнең чик күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Өстәмә түләү күләме, процент |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары | 14 |
| Урта звено мәдәният хезмәткәрләре вазыйфасы | 28 |
| Әйдәп баручы буын мәдәният хезмәткәрләре вазыйфасы | 38 |
| Мәдәният учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы | 48 |

4.16. Билгеле бер вакыт (ай, квартал, ел) өчен хезмәткәрләргә премиаль һәм башка кызыксындыру түләүләре бер тапкыр юбилей даталары уңаеннан, аерымлык билгеләре, Рәхмәт хатлары, грамота, дәүләт бүләкләре алу уңаеннан һәм оешманың локаль актлары һәм коллектив шартнамәләр белән билгеләнгән башка нигезләр буенча.

4.17. Премиаль һәм башка кызыксындыру чаралары, шул исәптән муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында бер тапкыр билгеләнә ала.

4.18. Премия һәм башка кызыксындыру түләүләрен гамәлгә ашыру күләме, тәртибе һәм шартлары МКУ «Мәдәният бүлеге» белән килештереп учреждениенең локаль норматив хокукый актлары һәм күмәк шартнамәләр белән билгеләнә.

## V. Учреждение Җитәкченең, җитәкчесе урынбасарының хезмәт хакын билгеләү тәртибе

5.1. Учреждение Җитәкченең, җитәкчесе урынбасарының хезмәт хакы җитәкче компенсация характерындагы һәм вазыйфаи окладларыннан һәм урынбасарларның кызыксындыру характерындагы түләүләрдән тора.

5.2. Мәдәният учреждениесе җитәкчесенең окладлары хезмәткә түләү буенча төркемгә карап елга бер тапкыр мәдәният учреждениесен гамәлгә куючысы тарафыннан билгеләнә. Мәдәният учреждениесе җитәкчесе хезмәтенә түләү төркеме мәдәният учреждениесе хезмәткәрләренең штат санына карап билгеләнә.

5.3. Җитәкчеләр урынбасарларының окладлары әлеге учреждениеләр җитәкчеләренең

вазыйфаи окладларыннан 20-30 процентка кимрәк билгеләнә.

5.4. Җитәкчеләр хезмәтенә түләү төркеме, җитәкчеләрнең окладлары күләме 5 нче таблицада күрсәтелгән.

5нче таблица

Мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренең окладлары

| Учреждениеләр тибы | Хезмәт өчен түләү төркеме | Аена оклад күләме, мең сум | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | Хезмәткәрләр штаты, кеше | 10га кадәр | 11 - 30 | 31 - 50 | 51 - 75 | 76-150 | 151 - 300 | 301-500 | 500 дән артык |
| Китапханәләр | | | 23,0 | 30,0 | 33,5 | 37,0 | 45,0 | 50,0 | |
| Клублар | | 21,0 | 27,5 | 30,0 | 33,5 | 35,0 | 40,0 | 50,0 | |
| Музейлар | | 22,5 | 26,5 | 28,0 | 35,0 | 37,0 | 45,0 | 50,0 | |
| Мәдәни-ял үзәге | | | 32,0 | 33,0 | 35,0 | | | | |

5.5. Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә расланган компенсация характерындагы түләү төрләре исемлеге нигезендә билгеләнә.

5.6. Кызыксындыру характерындагы түләүләргә учреждениенең билгеләнгән хезмәт хакы фонды чикләрендә гамәлгә куючы билгеләгән айлык премияләр керә.

VI. Кызыксындыру характерындагы түләүләр.

6.1. Учреждениеләрдә компенсация характерындагы түләүләргә түбәндәгеләр керә:

белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләүләр;

авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка үзенчәлекле хезмәт шартлары белән эшләүдә мәшгуль хезмәткәрләргә түләүләр;

нормаль эштән читкә киткән шартларда (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрнең (вазыйфаларның) бергә кушылуы), арттырып башкарылган эш, төнге вакытта эшләү һәм нормаль эштән читкә киткән башка шартларда эшләү өчен түләү.

6.2. Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, килешүләр, локаль норматив

актлар белән билгеләнә.

6.3. Белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләү мәдәният хезмәткәрләренә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_S — D_{sm} \times S,$$

монда:

$Bsm$ - белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләү;

$D_{sm}$ - белгечләргә авыл җирендә эшләгән өчен түләү күләме 1 388,5 сум тәшкил итә;

$S$- мәдәният хезмәткәре биләгән ставкаларның факттагы саны.

6.4. Авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка үзенчәлекле хезмәт шартлары белән эшләүдә мәшгуль хезмәткәрләргә һәм нормаль эштән (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрнең (вазыйфаларның) бергә кушылуы, арттырып башкарылган эш, төнге вакытта эшләү һәм нормаль эштән читкә авышкан башка шартларда эшләр башкарганда) читкә киткән шартларда эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Bkh = Od \times Dkh \times \frac{Hfsd}{Hn}$$

монда:

$B_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүләр ;

$O_d$ - мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләү өчен өстәмә түләүләр күләме;

$Hfsd$ ~ закон буенча компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт;

$H_n$ - Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителә торган мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт хакының (база оклады) база ставкасы өчен сәгать нормасы.

6.5. Авыр эшләрдә, зарарлы һәм (яки) куркыныч һәм башка үзенчәлекле хезмәт шартлары белән эшләүдә мәшгуль хезмәткәрләргә һәм нормаль эштән (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрнең (вазыйфаларның) бергә кушылуы, арттырып башкарылган эш, төнге вакытта эшләү һәм нормаль эштән читкә авышкан башка шартларда эшләр башкарганда) читкә киткән шартларда эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

төнлә һәр эш сәгате нормаль шартларда эшләү белән чагыштырганда, югарырак күләмдә түләнә, әмма Россия Федерациясенең законнар һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән күләмнән ким түгел;

хезмәткәр эшкә җәлеп ителгән очракта үзенә билгеләнгән график буенча ял көне яки эшләми торган бәйрәм көне өчен эш икеләтә күләмдә түләнә;

хезмәт окладын алучы хезмәткәрләргә, ял һәм эшләми торган бәйрәм көне эш вакытының айлык нормасы чикләрендә башкарылса, бер көнлек яки сәгать база окладыннан да ким булмаган күләмдә һәм эш бер айлык нормадан артып китсә, ике сәгатьлек яки көндезге ставкадан да ким булмаган күләмдә хезмәт хакы түләнә.

6.6. Ял яки эшләми торган бәйрәм көнендә эшләгән хезмәткәрнең теләге буенча аңа башка ял көне тәкъдим ителергә мөмкин. Бу очракта эш эшләми торган бәйрәм көне өчен бер генә күләмдә түләнә, ә ял көне өчен түләү каралмаган.

6.7. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләүче мәдәният хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү окладлар (вазыйфаи окладлар) белән чагыштырганда, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә төрле эш төрләре өчен билгеләнгән хезмәт хакы ставкалары белән чагыштырганда югарырак күләмдә билгеләнә.

6.8. Социаль хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Россия өчьяклы комиссиясе фикерен исәпкә алып, Россия Федерациясе Хөкүмәте зарарлы, куркыныч һәм башка үзенчәлекле хезмәт шартлары белән авыр эшләр исемлеген билгели.

## VII. Муниципаль китапханәләр, музейлар һәм мәдәни-ял учреждениеләре хезмәт хакы фондын формалаштыру тәртибе.

7.1. Муниципаль китапханәләр, музейлар, мәдәни-ял учреждениеләре хезмәте өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс чыгымнары нормативы, кулланучылар һәм хезмәтләр саны нигезендә билгеләнгән агымдагы финанс елына мәдәният учреждениесе чаралары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм мәдәният учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагылдырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләренең, музейларның, музей тибындагы башка учреждениеләрнең һәм мәдәни-ял учреждениеләренең мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Кагыйдәнамәгә

Кушымта

**Кызыксындыру характерындагы түләүләр бирелә торган Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы Союз һәм автоном республикаларның мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре**

**Исемлеге**

| № | Мактаулы исем, дәүләт бүләкләре исемнәре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| | 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре |
| 1.1. | Россия Федерациясенең халык артисты |
| 1.2. | Россия Федерациясенең халык рәссамы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган артисты |
| 1.4. | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |
| | 2. Татарстан Республикасы мактаулы исемнәре, дәүләт бүләкләре |
| 2.1. | Татарстан Республикасының халык артисты |
| 2.2. | Татарстан Республикасы халык язучысы |
| 2.3. | Татарстан Республикасының халык шагыйре |
| 2.4. | Татарстан Республикасының халык рәссамы |
| 2.5. | Татарстан Республикасының атказанган артисты |
| 2.6. | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 2.7. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| | 3. Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре |
| 3.1. | СССРның халык артисты |
| 3.2. | СССРның халык рәссамы |
| | 4. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында союздаш республикаларның мактаулы исемнәре |
| 4.1. | Атказанган пропагандачы |
| 4.2. | Халык артисты |
| 4.3. | Атказанган артист |
| 4.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 4.5. | Халык рәссамы |
| 4.6. | Атказанган рәссам |
| 4.7. | Халык язучысы |
| 4.8. | Атказанган язучы |
| 4.9. | Халык шагыйре |
| 4.10. | Халык җырчысы |
| 4.11. | Халык акыны |
| 4.12. | Атказанган журналист |
| 4.13. | Атказанган мәдәният эшлеклесе |
| 4.14. | Атказанган мәдәни-агарту эшләре хезмәткәре |
| 4.15. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.16. | Атказанган китапханәче |
| 4.17. | Гамәли сәнгать остасы |
| 4.18. | Атказанган халык иҗаты мастеры |
| 4.19. | Атказанган фән эшлеклесе |
| 5. Совет Социалистик Республикалар Союзы составында автоном республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган төзүче |
| 5.2. | Халык артисты |
| 5.3. | Атказанган артист |
| 5.4. | Атказанган сәнгать эшлеклесе |
| 5.5. | Халык рәссамы |
| 5.6. | Атказанган рәссам |
| 5.7. | Халык язучысы |
| 5.8. | Атказанган язучы |
| 5.9. | Халык шагыйре |
| 5.10. | Атказанган журналист |
| 5.11. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.12. | Атказанган китапханәче |
| 5.13. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 5.14. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 5.15. | Атказанган фән эшлеклесе |